# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

# КАРАР

«21» 03 2022 ел  Яр Чаллы  №20

«ТР, Тукай районы, Ильичевский поселогы адресы буенча «Саулык» сәламәтләндерү комплексы территориясендә җылылык челтәрләрен һәм кайнар су белән тәэмин итү челтәрләрен реконструкцияләү» дәүләт экологик экспертиза объекты проект документлары материаллары буенча (күздә тотылган эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләүне башкаруга техник биремне, күздә тотылган эшчәнлек йогынтысын бәяләү материалларын да кертеп) иҗтимагый фикер алышулар (иҗтимагый тыңлаулар рәвешендә) үткәрү турында

«Экологик экспертиза турында» 1995 елның 23 ноябрендәге 174-ФЗ номерлы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 январендагы 7-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнарга, «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 29 мартындагы «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 31/10 номерлы карарына таянып, «Экологик экспертиза турында» 1995 елның 23 ноябрендәге 174-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы, Россия Федерациясе табигый байлыклар һәм экология министрлыгының 2020 елның 1 декабрендәге 999 номерлы боерыгы, «ОмегаПром» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең («ОмегаПром» ҖЧҖ) 2022 елның 9 мартындагы 305/2022 номерлы язма мөрәҗәгате нигезендә

## КАРАР БИРӘМ:

1. «ТР, Тукай районы, Ильичевский поселогы адресы буенча «Саулык» сәламәтләндерү комплексы территориясендә җылылык челтәрләрен һәм кайнар су белән тәэмин итү челтәрләрен реконструкцияләү» дәүләт экологик экспертиза объекты проект документлары материаллары буенча (күздә тотылган эшчәнлекнең

әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләүне башкаруга техник биремне, күздә тотылган эшчәнлек йогынтысын бәяләү материалларын да кертеп) иҗтимагый фикер алышулар (иҗтимагый тыңлаулар рәвешендә) оештырырга һәм үткәрергә.

2. Иҗтимагый фикер алышуларны бер көндә, 2022 елның 29 апрелендә 15.00 сәгатьтә үткәрергә, үткәрү урыны: ТР, Яр Чаллы ш., М.Җәлил пр., 46 адресы буенча Тукай муниципаль районының чыгышлар залы.

3. Эшчке төркем составын расларга (1 кушымта).

4. Гражданнарның проект буенча фикер алышуда катнашу тәртибен кушымтадагыча расларга (2 кушымта).

5. Иҗтимагый фикер алышуларны үткәрү өчен җаваплы итеп Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллинны билгеләргә.

6. Иҗтимагый фикер алышуларны үткәрү турында мәгълүматны «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырырга.

7. Әлеге карарны Тукай муниципаль районы, Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы рәсми сайтларында урнаштырырга.

8. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам

Муниципаль район Башлыгы Ф.М. Камаев

Тукай муниципаль районы Башлыгының 2022 елның 21 мартындагы 20 номерлы карарына 1 кушымта

Эшчке төркем составы

**Рәис:**

Хәбибуллин А.Р. – Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе, комиссия рәисе;

**Комиссия әгъзалары:**

1. Никитина О. А. – Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге башлыгы урынбасары;
2. Нәдершин А.Н. – Тукай муниципаль районы Башлыгының җир мәсьәләре буенча ярдәмчесе.
3. Сәетгәрәев Ф.М. – «СКС» МУП директоры;
4. Исхакова Г.Г. – Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге башлыгы;

Тукай муниципаль районы Башлыгының 2022 елның 21 мартындагы 20 номерлы карарына 2 кушымта

Гражданнарның фикер алышуда катнашу тәртибе

Әлеге тәртип «ТР, Тукай районы, Ильичевский поселогы адресы буенча «Саулык» сәламәтләндерү комплексы территориясендә җылылык челтәрләрен һәм кайнар су белән тәэмин итү челтәрләрен реконструкцияләү» дәүләт экологик экспертиза объекты проект документлары материаллары буенча (күздә тотылган эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләүне башкаруга техник биремне, күздә тотылган эшчәнлек йогынтысын бәяләү материалларын да кертеп) иҗтимагый фикер алышуда катнашу, шулай ук халык фикерен исәпкә алу тәртибен жайга сала.

1. Гражданнарның проект буенча фикер алышуда катнашуы иҗтимагый фикер алышуларда катнашу һәм район халкының проект буенча тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен язма рәвештә Тукай районы Башкарма комитетына җибәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.
2. Проектның график һәм текст рәвешендәге материаллары Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты бинасында, мәгълүмат стендларында һәм Тукай муниципаль районы сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырылган.
3. Проект буенча материаллар белән танышу вакыты: дүшәмбе – җомга 9.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр (12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр төшке аш).
4. Язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2022 елның 28 мартыннан 2022 елның 20 маена кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: ТР, Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил пр., 46 йорт, Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты бинасы, 203 кабинет.
5. Иҗтимагый фикер алышуларны үткәрү өчен җаваплы зат иҗтимагый фикер алышуларны әзерли һәм үткәрә, шулай ук гражданнарның проект буенча тәкъдимнәрен кабул итә һәм исәпкә ала.
6. Иҗтимагый фикер алышулар секретаре проект буенча фикерләрне, тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алуны документлар белән тәэмин итә.
7. Иҗтимагый фикер алышулар башланганчы, секретарь иҗтимагый фикер алышуларда катнашучыларны терки. Теркәү битендә иҗтимагый фикер алышуларда катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы, яшәү урыны күрсәтелә.
8. Иҗтимагый фикер алышулар уздырганда түбәндәге регламент билгеләнә:
   - чыгыш ясаучыга төп доклад өчен 20 минутка кадәр вакыт бирелә;
   - проект буенча фикер алышуга – 3 минутка кадәр;
   - фикерләрне кире кагу һәм искәрмәләр өчен – 2 минутка кадәр.
9. Иҗтимагый фикер алышулар үткәрү барышында секретарь тарафыннан иҗтимагый фикер алышулар беркетмәсе алып барыла.
10. Иҗтимагый фикер алышулар беркетмәсе иҗтимагый фикер алышулар уздырылган көннән соң 5 эш көне эчендә әзерләнә һәм мәҗбүри рәвештә Тукай муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.